СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.2, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 2 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

“02” октябрь 2017 ел. | № 1-25

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 5 номерлы карары, Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 3-24 номерлы карары, Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2014 нче елның 02 че апрелендә кабул ителгән 2-33 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советы

К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2017 нче елның 19 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм икенче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. 1.Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:
   Жюри, Түбән Шүләңгер, Комаровка авылларында су башняларын койма белән әйләндереп алу;
2. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
   Уткино торак пунктында туфрак белән капланган юлларны ремонтлау, Нагорная урамы 60 м., Зори торак пункты, Заречная урамы 200 м.;
3. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:
   янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру:
   Түбән Шүләңгер торак пунктында 2 шт.;
   Зюри торак пунктында 5 шт.;
4. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:
   Березовая Поляна торак пунктында урам яктырту объектларын модернизацияләү (агымдагы ремонт, урам яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру);
   Урта Шүләңгер торак пунктында чишмәне төзекләндерү.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы Е.М.Михайловага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /Е.М.Михайлова/